РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«08» ноябрь 2022 ел** **№ 7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 18.04.2012 ел №35 (16.02.2015 ел №114, 05.09.2015 ел №132, 03.03.2016 ел №26, 10.04.2018 ел №84 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты – 2022 елның 29 ноябре 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны – Илбәк авылы, балалар уен мәйданчыгы торриториясе;
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru. адресы буенча 2022 елның 09 ноябреннән дә соңга калмыйча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина